| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЫСОКОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**Отдел образования**<br>422700, пос.ж/д ст. Высокая Гора,<br>ул. Школьная , 17<br>тел. (8-265)2-36-06, факс (8-265)2-36-00, | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>**Мәгариф бүлеге**<br>422700, Биектау тимер юл станциясе поселогы,<br>Мәктәп урамы, 17<br>тел. (8-265)2-36-06, факс (8-265)2-36-00 |
|---|---|---|


№ 1004 от 28.11.2023

**Муниципаль районнарның**
**мәгариф бүлекләре,**
**белем бирү оешмалары**
**җитәкчеләренә**

Хәй Вахит исемендәге
әдәбият һәм сәнгать районара бәйгесен үткәрү турында

Күренекле драматург, шагыйрь, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Габделкаюм улы Габделхәй Вахитовның (Хәй Вахит) тууына 105 ел тулуга багышлап «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе Хәй Вахит исемендәге әдәбият һәм сәнгать районара бәйгесен үткәрә.

Белешмәләр өчен телефоннар: «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең милли мәгариф буенча методисты Юнысова Сәлимә Фәндүс кызы (884365 2 36 02); «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Җамалиева Ләйсән Ильяс кызы (89872897610).

Кушымта: нигезләмә 3 биттә 1 нөсхәдә.

Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары –
“ТР Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының мәгариф бүлеге”
муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.К.Әхмәтҗанов

Юнысова С.Ф.
(884365) 2 36 02

Кушымта

**Хәй Вахит исемендәге әдәбият һәм сәнгать районара бәйгесе**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

Нигезләмә Хәй Вахит исемендәге әдәбият һәм сәнгать районара бәйгесенең (алга таба – **Бәйге**) максатларын һәм бурычларын, шартларын һәм үткәрү тәртибен билгели.

**Бәйге** күренекле драматург, шагыйрь, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Габделкаюм улы Габделхәй Вахитовның (Хәй Вахит) тууына 105 ел тулуга багышлана.

## 2. БӘЙГЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**Бәйге**нең төп максаты: танылган драматург Хәй Вахитның иҗатын таныту, аның исемен мәңгеләштерү, бөек шәхесебезнең татар театрына, җыр сәнгатенә булган мөнәсәбәте нигезендә яшь буынны тәрбияләү.

**Бәйгенең** бурычлары:

- укучыларда милли үзаң формалаштыру аша Хәй Вахитның иҗади мирасын өйрәнү;
- укучларның осталыкларын камилләштерүдә һәм иҗади үсеш өчен укучыларга шартлар тудыру;
- иҗатка сәләте булган яшьләрне барлау, таныту һәм сәләтләрен үстерү.

## 3. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

**Бәйгене** оештыручылар:

- Татарстан Республикасының Язучылар берлеге;
- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;
- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе;

Оештыру комитеты «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе мәктәп укучылары һәм укытучылар игътибарына мәгълүмати хатлар, электрон сайт аша бәйгене үткәрү турындагы мәгълүматны җиткерә; катнашучыларның эшләрен җыюны һәм жюри эшчәнлеген оештыра, бүләкләү тантанасын үткәрә.

## 4. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Бәйгедә Татарстан Республикасының Биектау, Арча, Әтнә, Яшел Үзән мәктәпләре укытучылары һәм укучылары катнаша ала.

4.2. Бәйге түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

4.2.1 Укытучылар өчен "Тәҗрибә" юнәлеше.

"*Мәктәптә якташ язучылар иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән*" темасына мастер-класс эшкәртмәләре, чыгышлар кабул ителә.

4.2.2. Укучылар өчен "*Әдәби иҗат*"юнәлеше.

"Театр яктылыкка, нурга илтә" һәм ирекле темага язылган шигырьләр, хикәяләр, пьесалар түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:

- 7-9 сыйныфлар,
- 10-11 сыйныфлар.

4.2.3. "*Хәй Вахит сәхнәсе*" юнәлеше.

Драматургның пьесаларын сәхнәләштерү.

4.2.4. "*Моң чишмәсе*" юнәлеше.

1) Хәй Вахит сүзләренә язылган җырларны башкару.
2) Татар халык җырларын башкару.

4.2.3 "*Туган ягымның күренекле шәхесләре*" темасына иншалар. (5-8, 9-11 нче сыйныф укучылары өчен).

4.3.Бәйгедә катнашучы 2023 елның 29 декабренә кадәр мастер-класс эшкәртмәсен, чыгышларны, авторлык әсәрләрен, видеоязмаларны, иншаны гариза белән бергә (үрнәге кушымтада) zamalieva75-18@mail.ru адресы буенча, оештыру комитетына җибәрә:

**Игътибар!!! Хат исемендә кайсы юнәлешкә икәнлеге күрсәтелергә тиеш.**

4.4. Бәйге ике турда үткәрелә:

**1 нче тур ( читтән торып катнашу**). Экспертлар төркеме, 2 нче турда катнашу өчен, һәр юнәлештән эшләрне сайлап ала. Беренче тур «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе сайтына урнаштырыла.

**2 нче тур** 2024 нче елның 26 нчы гыйнварында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә түбәндәге эш юнәлешләре буенча үткәрелә:

1) Укытучылар өчен "Тәҗрибә" юнәлеше.

"*Мәктәптә якташ язучылар иҗатын өйрәнү тәҗрибәсеннән*" темасына мастер-класс эшкәртмәләре, чыгышлар. (Чыгыш ясау вакыты: 5-7 минут).

2) Укучылар өчен "*Әдәби иҗат*"юнәлеше.
3) "*Хәй Вахит сәхнәсе*" юнәлеше. (Чыгыш ясау вакыты: 5-7 минут).
4) "*Моң чишмәсе*" юнәлеше. (Чыгыш ясау вакыты: 3-4 минут).

4.5. Бәйге җиңүчеләре дипломнар белән бүләкләнәләр. Катнашучыларга электрон дипломнар җибәреләчәк.

4.6. Конференция нәтиҗәләре «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Һәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе сайтында урнаштырылачак.

*Кушымта*

Катнашу өчен заявка үрнәге

1. Укытучылар өчен

| Укытучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме | Устав буенча мәктәп исеме | Чыгышның темасы | Электрон почта адресы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

2. Укучылар өчен

| Катнашучы укучының исем-фамилиясе | Сыйныфы | Устав буенча мәктәп исеме | Кайсы юнәлештә катнашуы турында мәгълүмат | Тема | Укытучысы турында мәгълүмат | Электрон почта адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

3. “Һәй Вахит сәхнәсе”, “Моң чишмәсе” юнәлешләре

| Устав буенча мәктәп исеме | Катнашучылар турында мәгълүмат | Видеофайлны карау өчен ссылка | Электрон почта адресы |
|---|---|---|---|
| | | | |